КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 9 апрель г.Казань № 228

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 елда республика күзәтүе формаларын, социологик тикшеренүләр исемлеген раслау турында» 2021 ел, 28 гыйнвар, 32 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 елда республика күзәтүе формаларын, социологик тикшеренүләр исемлеген раслау турында» 2021 ел, 28 гыйнвар, 32 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта:

егерме өченче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«2021 елда Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм җирле үзидарә органнары өчен Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан «Ачык Татарстан» мәгълүмат порталының «Ведомстволар хисаплары» исәп-хисап системасында яисә Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәтенең эчке контурында «Мәгълүмати статистик ресурс» рубрикасында https://ias.tatar.ru. адресы буенча урнаштырыла торган социаль-икътисадый мониторинг нәтиҗәләре буенча белешмә материаллар исемлеге»;

әлеге карар белән расланган «Хезмәт хакы күләмнәре буенча хезмәткәрләр санын бүлү турында белешмәләр» 1 нче республика күзәтүенең (елга 1 тапкыр) формасын яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә);

әлеге карарга 2021 елда Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм җирле үзидарә органнары өчен Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан «Ачык Татарстан» мәгълүмат

порталының «Ведомстволар хисаплары» исәп-хисап системасында яисә Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәтенең эчке контурында «Мәгълүмати статистик ресурс» рубрикасында https://ias.tatar.ru. адресы буенча урнаштырыла торган социаль-икътисадый мониторинг нәтиҗәләре буенча белешмә материаллар исемлеген өстәргә (кушымтада бирелә).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин